# ГРАЖДАННАР ҖЫЕНЫ КАРАРЫ

2025 елда Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль районы Илбәк авыл җирлеге Илбәк торак пунктында гражданнардан үзара салым кертү турында

**19 сентябрь 2025 ел** **№ 2**

2003 елның 06 октябрендәге 131-ФЗ номерлы «Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» Федераль законның 25.1, 56 статьясы, 2004 елның 28 июлендәге 45-ТРЗ номерлы “Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында” Татарстан Республикасы Законының 35 статьясы нигезендә Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль районының Илбәк авыл җирлеге Илбәк торак пунктында гражданнар җыены

**КАРАР ИТТЕ:**

1. «22.11.2024 ел, №1 «Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль районы Илбәк авыл җирлегенең Илбәк торак пунктында гражданнар җыены нәтиҗәләре турында», 22.11.2024 ел, № 2 «Азнакай муниципаль районы Илбәк авыл җирлегенең Илбәк торак пунктында 2025 елда гражданнарга үзара салым кертү турында» карарларына, чараларны түбәндәге редакциядә бәян итеп, үзгәрешләр кертергә:

« - Илбәк торак пунктында урам яктырту челтәрләрен, трансформатор һәм башка подстанцияләрне һәм алар астындагы мәйданчыкларны, бүлү пунктларын һәм электр элемтәләрен тәэмин итү һәм электр энергиясен тапшыруны гамәлгә ашыру өчен билгеләнгән башка җиһазларны ремонтлау (лампалар, яктырткычлар, электр товарлары һәм махсус җиһазлар сатып алу, алмаштыру);

- торак пункт чикләрендә җирле әһәмияттәге гомуми файдаланудагы автомобиль юлларын төзекләндерү, ремонтлау, карап тоту (Илбәк авылында Ә. Вәлиев урамындагы 35 нче йорттан 39 нчы йортка кадәр вак таш түшәлгән юлны профильләштерү);

- Илбәк торак пункт территориясен төзекләндерү (тракторчыга механикалаштырылган кар җыю буенча хезмәтләр өчен түләү, торак пункт чикләрендә җирле әһәмияттәге юлларны карап тоту буенча чит оешмалар хезмәтләре).”

2. Әлеге карарны, кабул ителгәннән соң 10 көн эчендә Илбәк авылы, Ә.Вәлиев урамы, 10а йорт; Илбәк авылы, Ә.Вәлиев урамы, 50 йорт адреслары буенча урнашкан мәгълүмат стендынларында урнаштырырга һәм Азнакай муниципаль районының рәсми сайтында (http://aznakaevo.tatarstan.ru), хокукый мәгълүматның рәсми сайтында (http://aznakaevo.tatarstan.ru) урнаштыру юлы белән игълан итәргә.

Халык җыенында рәислек итүче,
Азнакай муниципаль районы
Илбәк авыл җирлеге башлыгы Р.К.Галимҗанова